УРТАК ЭШ
Быелтыр Татарстан белән Үзбәкстан арасында товар әйләнеше 50 процентка арткан

> 2

ҖАВАПЛЫ ҺӘМ САВАПЛЫ
Бөтен дөньядан җыелган хатын-кызлар милләтне саклау турында сөйләште

> 3

ӨЗЕЛГӘН ТЕЛ
Камал театрының яңа спектаклендә танышларны да күрергә мөмкин

> 4

АВЫЛ ЯЗМАЛАРЫ
Тәртип белән өелгән һәр чүп-чар матурлык булып тоела икән

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 58 (29025) | Сишәмбе | 25 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

АШЛЫ КАШЫК

ҖӘЕН КҮПМЕ БАЛА ЭШКӘ УРНАШАЧАК?

Илдә һәр бишенче бала җәйге каникулын эшләп үткәрергә җыена. Узган ел белән чагыштырганда, андыйлар дүрттән бер өлешкә күбрәк. SuperJob үзәге уздырган сораштыру нәтиҗәләре шуны күрсәтә. Быел республикада 14 мең үсмергә эш бар. Яшьләр кесә калынайтырга әзерме?

Җәен үсмерләр арасында курьер, пешекче, әйдәман булып эшләү популяр. Казанда яшәүче 14 яшьлек Регина Хафизова теш кую үзәгенә урнашмакчы. Әлбәттә, техник булып түгел, документлар тәртипләргә чакырган аны оешма хуҗасы.

– Язгы каникулда апама документлар тәртипләргә булышырга барган идем. Заказлар күп булгач, кәгазьләр рәтләргә вакыты калмый. Бер күчкә өелгән. Җаваплы эш, бер генә документны да бутарга ярамый. Тәртипсезлек яратмыйм. Менә шуларны җайга салдым. Җитәкче канәгать калды, җәйге каникулда эшләргә чакырды. Әлбәттә, ризалаштым, – ди Регина.

КФУ студенты Исламия Сафина быел да «Сәләт» лагерена әйдәман булып бармакчы. Узган ел шунда тәүге акчасын эшләгән.

– 18 көнлек сменада эшләгән өчен 13 мең сум түлиләр. Форумда эшләү файдалырак, акчасы күбрәк. Укуны бетергәч, сәлкешләр янына китәчәкмен. Теләк кенә кирәк. Бүгенге яшьләргә төрле өлкәләрдә акча эшләү мөмкинлеге бар, – ди Исламия Сафина.

Әлмәтнең халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә эшкә урнаштыру бүлеге җитәкчесе Дилором Матвеева әйтүенчә, узган ел җәйге чорда шәһәрдә 345 үсмер хезмәт куйган. Быел күпме егет-кызның тир түгәчәге май аенда билгеле булачак.

– Балаларны эшкә урнаштырырга теләгән оешмалардан гаризалар кабул итәбез. Әлегә андыйлар – 12. Алар арасында шәһәрне төзекләндерү, юллар төзү оешмалары, «Водоканал», металлургия заводы һәм башкалар бар, – ди бүлек җитәкчесе. – 1 июнь – Халыкара балаларны яклау көне уңаеннан, шәһәрдә ел саен укучылар катнашында мәктәп ярминкәсе үткәрәбез. Эш күп анысы. Яшьләрнең дә азмы-күпме кесә ягын калынайтасы килә. Тик оешма җитәкчесеннән дә күп нәрсә тора. Үсмерләрне эшкә алу – зур җаваплылык. Һәрберсенә остазлар беркетергә кирәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Балтач районының «Борнак» җәмгыяте җитәкчесе Рәфкать Нәҗипов белдергәнчә, соңгы вакытта җәен 2–3әр бала эшли. Элек алар 5–6 тапкыр күбрәк булган. Малайлар көтү көтәргә чират торган, хәзер замана башка.

– Балалар амбарда, фермада булыша. Үсмерләр көнгә 4–5 сәгать эшли. Айга 17–18 мең сум хезмәт хакы ала. Телефонда утырганчы, бер-берсе белән аралаша. Арпа белән арышны аерырга өйрәнә, – ди Рәфкать Нәҗипов. – Эш бар ул, хәзер авылда балалар аз. Әти-әниләрнең дә җәйге чорда ул-кызларын ял иттерәсе килә. Аннан үсеп җиткәч, каян килә эш рәте белмәгән яшьләр, дип аптырыйлар. Җәйге каникулда каядыр хезмәт куйсалар, бик әйбәт.

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хәбәр иткәнчә, оешмалар үсмерләрне елга буйларын, урманнарны чистарту, агач утырту, чүп утау, һәйкәлләрне карап тоту кебек эшләргә җәлеп итә. Шулай ук сәнәгать оешмалары, зоопарк, авыл хуҗалыгы өлкәсендә дә яшь көчләрнең кирәге чыга. 18 яше тулмаганнарны авыр хезмәткә, әйтик, җир асты эшләренә, сәламәтлеккә зыян китерә торган хезмәткә җәлеп итәргә ярамый.

Быел республикада 14–18 яшьлек егет-кызларны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен 31,2 миллион сум акча бүлеп бирелгән. Районнар да үз казнасыннан өлеш чыгара. Әйтик, узган ел 41,5 миллион сум акча тотылган, бу – 2021 ел белән чагыштырганда, 60,7 процентка күбрәк дигән сүз. Әмма былтыр Аксубай, Әтнә, Балтач, Зәй, Лениногорск, Мөслим, Саба районнары үсмерләрне эшкә урнаштыру өчен акча бүлеп бирмәгән.

Мәшгульлек үзәкләре үсмерләрнең 40 процентка якынын мәдәният, яшьләр һәм спорт, мәгариф бюджет оешмаларына эшкә урнаштыра. Бу очракта район бюджетларыннан акча бүлеп бирү мәсьәләсе карала. Былтыр 12392 үсмер мөрәҗәгать иткән. Алар арасында авыру, ятимнәр дә бар. Сүз уңаеннан, үзәк аша эшкә урнашканда, ай саен 2250 сум өстәп бирелә.

Һәр районда үсмерләрне эшкә урнаштыру күрсәткече шунда яшәүче яшьләрнең 10 процентыннан ким булмаска тиеш. Тик барлык районнар да аны үти алмый. Казан шәһәре, Биектау, Югары Ослан, Мамадыш, Ютазы районнарында укучыларны эшкә урнаштыру күрсәткече азрак булса, Кукмара, Лениногорск, Бөгелмә, Саба районнарында күбрәк. Балаларга хезмәт кадерен аңларга, кесәләрен калынайтырга мөмкинлек бирик.

Сан

КҮПМЕ ЭШЛӘРГӘ ЯРЫЙ?
➤16 яшькә кадәр – атнага 4 сәгатьтән артык түгел.
➤16–18 яшьтә – атнага 35 сәгатьтән артмаска тиеш.

Тукай бүләге – 1 млн сум

Быел Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең күләме 1 млн сум тәшкил итәчәк. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов имзалаган указда шул хакта әйтелә. Моңа кадәр әлеге премия 500 мең сум иде.

Мәгълүм булганча, быел Тукай бүләгенә 13 кандидат тәкъдим ителде. Лауреатларны 26 апрельдә – Тукай туган көндә узучы Туган тел көнендә бүләклиләр. 1958 елдан бирле тапшырылып барган бүләккә узган ел язучы Ләбиб Лерон һәм рәссам Анатолий Егоров лаек дип табылган иде.

Мәңгеләштерү

Җиңү бәйрәме алдыннан – 4 майда – Казанның Төньяк вокзалы янында «Казан – хезмәт батырлыгы шәһәре» steласы ачылачак. Биредә төп эшләр инде төгәлләнеп килә. Бөек Ватан сугышы елларында тылда Җиңүгә үзләреннән гаять зур өлеш керткән предприятиеләр ветераннарын һәм хезмәткәрләрен хөрмәтләү билгесе бу.

Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Рөстәм Гафаров әйтүенчә, иң элек балаларга «Казан – хезмәт батырлыгы шәһәре» мактаулы исеменең мәгънәсен аңлатырга кирәк. Стеланы алар истәлек баганасы буларак кына кабул итмәскә тиеш.

Скверда, стеланы ачудан тыш, «Хәтер бакчасы» акциясе дә узачак. Шулай итеп, Казанда яшәүчеләр, агачлар утыртып, Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерәчәк.

Кодлы акча

Россиядә ел азагына кадәр цифрлы акча әйләнешкә кертеләчәк. Илнең финанс министры Антон Силуанов әйтүенчә, моның өчен тиешле законнар кабул итү күздә тотыла.

Ул быел Үзәк банкның цифрлы сумны үстерү буенча эксперимент башлап җибәрүен билгеләп үткән. Исегезгә төшерәбез: «тере» акчадан (янчыкларыбыздагы кәгазь һәм вак акча), электрон акчадан (банклар счетларындагы, карталардагы) тыш, сумның өченче формасы – цифрлы сум (кодлар рәвешендә) пәйда булачак. Ул Россия банкы платформасында цифрлы янчыкларда сакланачак. Мондый акча белән алыш-бирешләр дә шушы платформада ук хәл ителәчәк. Цифрлы янчыкларга банкларның мобиль кушымталары, интернет-банклар аша кереп булачак. Белгечләр әйтүенчә, мондый акчаны мошенниклар урлый алмаячак.

Моңа кадәр Үзәк банк башлыгы Эльвира Нәбиуллина әйтүенчә, цифрлы сумны куллану-кулланмау кешенең үз ихтыярына бәйле булачак. Аннан файдаланучыларга аена 300 мең сумга кадәр цифрлы акча лимиты билгеләнә.

Бурычлы көн күрмәс

Ел башыннан бирле республика суд приставлары бурычлыларның мөлкәтенә (барлыгы 2 миллиард 52 миллион сумлык) арест салу буенча 3 меңнән артык беркетмә төзегән. Шул исәптән 1,1 миллиард сумлык милек: фатирлар, склад, гараж, машиналар «Росимущество» оешмасына аукционда мәҗбүри сатуга җибәрелгән. Сатудан кергән акча бурыч түләүгә тотылачак. Керем күләме бурычтан артып киткән очракта, аермасы бурычлы кешенең үзенә кире кайтарып биреләчәк.

Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе бурычның булу-булмауны мөстәкыйль рәвештә белешергә, суд приставларын көтеп утырмаска киңәш итә.

Бәйрәм көткәндә

Ярамыйга карыймы?

Май бәйрәмнәре халыкның кәефен кырмагае. Илнең кайбер төбәкләрендә киләсе озын ялларда хәмер сатуны гомумән тыярга тәкъдим иткәннәр. Бу мәсьәләнең ни өчен нәкъ менә хәзер калкып чыгуы да аңлашыла. Татарстандагы рәсми саннарга гына ышансаң да, халык нәкъ менә апрель, май һәм июнь айларында күбрәк эчә икән. Тыяргамы, юкмы?

Илнең берничә төбәгендә Май бәйрәмнәренә «коры закон» керткәннәр. Мәсәлән, Курган өлкәсендә 1 һәм 9 Майда кибеттән алкогольле эчемлекләр, шул исәптән сыра да сатып алып булмаячак. Халыкка ни өчен аек йөрергә туры киләчәген дә аңлатканнар. Беренчедән, бәйрәм арасында имгәнү очраклары бермә-бер артса, икенчедән, табигатькә чыгып кәеф-сафа корырга теләүчеләр санын киметмәкчеләр. Курган өлкәсендә илнең күп кенә төбәкләрендәге кебек үк янгынга каршы куркынычсызлык режимы гамәлдә. Шешә күтәреп, шашлык пешерүчеләр «кызыл әтәч»нең учактан коры үләнгә сикергәнен сизми дә калырга мөмкин. Хәмерне җәмәгать туклануы урыннарында гына салып бирәчәкләр. Шунысын да әйтик: Курган өлкәсендә былтыр да Май бәйрәмнәрендә «коры закон» гамәлдә булган.

Бәйрәм арасында Екатеринбургта да алкогольле эчемлекләр сатуны туктатып торачаклар. Якутскида 1 Май бәйрәме чын хезмәт бәйрәменә әверелер, мөгаен. Чөнки бу көнне шәһәрдә хәмер, шул исәптән сыра сатылмаячак.

Барнаулда исә Май бәйрәмнәрендә спиртлы эчемлекләр сату вакытын чикләгәннәр. «Коры закон» керткән төбәкләр исемлеге тагын да зураерга мөмкин, ди белгечләр. Чөнки әлеге мәсьәләне һәр төбәк үзе хәл итә, ди. Үрнәк күрсәтүчеләр бар бит инде. Татарстанда яшәүчеләрне бәйрәм арасында ни көтәчәген белергә теләп, Татарстан Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына да шалтыраттык. Бу хакта мәгълүмат юк, диделәр.

Тыярга кирәкми эчәргә. Бу җөмләдә өтерне кая куярга икәнен халык арасында үткәрелгән сораштыру барышында да ачыклый алмаганнар. Фикерләр икегә бүленгән. Хәмер сатуны тыюга каршы булучылар: «Һәркем ничек тели, шулай ял итәргә хокуклы», – дип белдерсә, моны хуплаучылар, эчеп кырылабыз, дип чаң суга.

Соңгылары белән килешмичә дә булмый. Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе мәгълүматларына караганда, былтыр республикада 5,84 мең декалитр исерткеч эчемлек сатылган. Алдагы ел белән чагыштырганда, әлеге күрсәткеч 4 процентка арткан. Хәмер сатып алучылар республиканың барлык районнарында да күбрәк теркәлгән. Барыннан да бигрәк, Кайбыч районында (+24%) яшәүчеләр тырышкан. Бу урында әлеге районда «гасыр төзелеше» алып барылуын да исәпкә алырга кирәктер. Күрсәткечләр Югары Ослан, Чүпрәле һәм Яңа Чишмә районнарында да (һәркайсында +20%) сизелерлек арткан. Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә былтыр 4 процентка күбрәк спиртлы эчемлек сатылган. Әлки районында хәмер сату күләме узган ел дәрәҗәсендә калса, Татарстандагы 43 район арасында бердәнбер Актанышта әлеге күрсәткеч 3 процентка кимегән.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Борис ТИТОВ, Россия Президенты каршында эшкуарларның хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:

Үзмәшгульләр эшкуарлар белән бер үк дәрәҗәдә булмаса да, алар ялланган эшчеләр дә түгел. Матди хәлләре фәкать үзләреннән генә тора. Шуңа күрә үзмәшгульләргә күбрәк юнәлеш буенча эшләү мөмкинлеген тудырырга кирәк. Югыйсә бүген лицензия алып эшли торган бер генә өлкәдә дә үзмәшгульләргә урын юк.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫ

Татарстанның 13 югары уку йорты илнең иң яхшы вузлары рейтингына кергән. hh.ru сайты оештырган тикшеренү шуны күрсәтә.

1 >> Икътисад югары мәктәбе / 2 >> РАНХиГС / 3 >> «Синергия» / … / 5 >> КФУ

117 – КГЭУ	…	…
…	190 – КГАУ	312 – АГНИ
144 – КНИТУ	191 – ТИСБИ	313 – КГМУ
…	…	…
149 – КНИТУ-КАИ	198 – КазГИК	328 – КГАВМ
…	…	…
178 – КИУ	299 – КГАСУ	368 – ПГУФКСиТ

Реклама 16+

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 10–27 апрель көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — **Ташламалы бәя** 444 сум 54 тиен — гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** 1051 сум 80 тиен — гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЙЕЛЛЕН КАТАСТРОФА ФАРАЗЛЫЙ

Глобаль дөньяда, кызганыч, вакыйгалар зур хәвеф спирале рәвешендә бөтерелә. Дәүләтләр килеп туган проблемаларны уртак тел табу аша чишү юлыннан баш тарта. Социаль катастрофа, хәрби каршылыкларның үсүе, базарларның бер-берсенә аяк чалуы чорның төп билгесенә әверелеп бара. Боларның һәлакәткә китерәчәген һәркем аңлый, әмма вакыйгалар фаҗигале рәвештә шул эздән бара.

АКШның финанс министры Йеллен Кытай белән араны өзүнең катастрофага илтәчәген әйтеп: «Икътисадларны тулысынча аеру ике ил өчен дә һәлакәт булыр иде. Бу калган бар дөнья өчен дә тотрыклылыкны юкка чыгаручы фактор булачак», – дигән фараз ясады. Тайваньның тышкы эшләр министры да: «Кытай һәм Тайвань арасындагы сугыш дөнья сәүдәсен 40 процентка киметергә мөмкин», – дигән сүзләр әйтте. Тайбей дөньякүләм ярымүткәргечләр җитештерүенең 60 процентын үз кулында тота, аларның иң заманчаларының 90 проценты шунда конвейердан төшә. Министр шуңа басым ясый.

Дөнья икътисады зур сугыштан башка да мәтәлчек ату юлында. Аргентинаның Үзәк банкы төп ставканы 81 процентка кадәр күтәрде, чөнки инфляция котырына. Атна ахырында биткоин 27 мең 400 долларга кадәр түбәнәйде. Ел башында 30 мең доллардан югарырак сикергән иде. Мисыр фунты, Иран риалы чүпкә әйләнеп баралар. Хәзерге вакытта 1 доллар 42 мең 250 риалга тигез. Бу гаҗәп түгел. Мисыр, мәсәлән, табышының яртысына якынын әҗәтләренең процентларын түләүгә тота. Ассызыклыйбыз: әҗәт түләүгә түгел, процентларын түләүгә. Дефолт исе килүен аңлау өчен белгеч булырга да кирәкми.

Нык үскән икътисадларда да хәл шуннан яхшы түгел. АКШ ФРСы, инфляция һәр җирдә, дип уфтана. JPMorgan банкы сораштырулары Америкада дефолт ихтималлыгы 35 процентка җитүен күрсәтә.

Конфронтациянең һәлакәткә илтүен аңлау дәүләтләрдә уртак тел табарга омтылыш тудырмый ләкин. Германиянең тышкы эшләр министры Анналена Бербок Кытайга сәфәреннән соң аның нәтиҗәләрен «шок тудыра торганнан да көчлерәк» дип бәяләде һәм Кытайның торган саен сәүдә партнеры түгел, ә системалы көндәшкә әверелә баруын әйтте.

Судан конфликты үткән атнада үсешен дәвам иттерде. Билгесез көчләр Хартумның (ил башкаласы) төньягындагы төрмәгә һөҗүм иттеләр. Күпсанлы тоткыннар качты, алар арасында түнтәрелгән элекке Президент әл-Бәшир дә бар, диделәр. Соңгы факт әлегә рәсми рәвештә расланмаса да, чынга охшаган. Үзара каршы торучы көчләрнең сугышы нәтиҗәсендә илдә тыныч халык кырыла, чит илләрнең дипломатик миссияләре һәм гражданнары да куркыныч астында. Дөньякүләм вазгыятьне Судан хәленә җиткермәскә иде.

Россиядә

РОССИЯ БЮДЖЕТЫ: ЧЫГЫМНАР ТАГЫН ҮСӘ

Федераль бюджетка очны очка ялгап бару көннән-көн авырая. Март аенда Мәскәү чыгымнарны киметә һәм дефицитсыз диярлек бюджетка ирешә алган иде. Апрельнең беренче декадасында ук көнлек бюджет чыгымнары кискен үсеп киттеләр. Казна акчасы гыйнвар – февральгә караганда да күбрәк исраф ителә башлады. 11–17 апрель аралыгында акча тоту таң калдырырлык дәрәҗәдә үсте. Бер атна эчендә 1,140 триллион сум акча тишек кесәдән төшеп калган кебек юкка чыкты. 17 көнлек чыгымнар – 2,068 триллионга, ел башыннан тотылган акча 10,144 триллион сумга җитте. Әйдәгез чагыштырабыз. Федераль бюджет гыйнвар аенда бер көнгә 97 миллиард сум акча тоткан. Февральнең көнлек чыгымнары – 98 миллиард сум. Март күрсәткече – 75 миллиард сум гына. Һәм апрель, ниһаять, барысын да уздырып, колачны киң җәйгән: бер көнгә тотылган акча 122 миллиард сумга җиткән. Бюджетта бер елга 29,867 триллион сумлык чыгымнар салынган. Бюджетны үтәү өчен (кәгазьдәгечә үтәлгәндә дә әле ул дефицитлы булачак) калган айларда тәүлеккә 76,4 миллиард сумнан артык акча тотарга ярамый. Бу сан үтәлер дип уйлау шик тудыра. Милли байлык фонды быелга җитәрлек әле, билгеле. Әмма Мәскәүдә аны быел ук тотып бетерүдән сакланачаклар. Бюджетны тутыруның популяр булмаган башка юлларын сайларга туры килер, мөгаен. Бу – салымнарны арттыру, инфляция, девальвация. Агымдагы вазгыятьтә инфляция түбәнәйде. Ул хәтта Үзәк банк омтылган параметрдан дә түбәнгәрәк китте, 3 процент тирәсе генә. Аны акча басып күтәрергә мөмкин. Салымнарны арттыру, сумның курсын түбәнәйтү җитештерүчеләр өчен проблемалар тудырачак. Девальвация тагын бер проблема белән яный. Россиядә эшче куллар җитешми. Гайдар институты эшче куллар дефицитын соңгы утыз елда иң көчлесе дип бәяли. Эшкә кеше булмаса, җитештерүне үстерү мөмкин түгел. Дефицитны мигрантлар белән капларга гадәтләндек. Әмма төрле чыганаклардан алган саннар Россиядә мөһаҗирләр саны кимүен дә күрсәтә. Чит ил кешесе безгә ни өчен килә? Акча эшләү өчен. Һәм аңа хезмәт хакының доллардагы күләме мөһим. Девальвация хезмәт хакының валютадагы күләмен кечерәйтә. Бездә эшләп алган акчасы мөһаҗир өчен кызыктырырлык булудан туктый. Шул сәбәпле хөкүмәтне валюта курсларын уйнатканда бик игътибарлы булырга мәҗбүр итә. 2014 елдагыча паника ясап, доллар курсын ике тапкыр сикертсәң, мигрантлар хезмәтен файдалану мөмкин булмавы ихтимал. Хәзер мөһаҗирләр көч түкмәгән тармакны табу кыен. Ташкичүдә дә берничә таҗик егете эшли. Алардан башка ферма ятим калачак.

Төбәк бюджетлары да акча агымнарының саегуыннан интегәләр. 85 төбәкнең 33ендә үткән ел ахырында казнага түләүләр кискен кимегән. 5 төбәктә салым җыю һәлакәтле чиккә кадәр түбәнәйгән, диләр белгечләр. Бары тик 17 төбәктә генә салым җыю арткан.

БЕР КҮРЕШҮ – ҮЗЕ БЕР МАКСАТ

Рәис сәфәре

290 миллион доллар. Былтыр Татарстан белән Үзбәкстан арасында товар әйләнеше 50 процентка арткан. Бу да чик түгел. Үзбәкстанга эш сәфәре белән барган Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов яңа технопарк ачылышында катнашты.

tatarstan.ru

Яңа сәнәгать мәйданы Үзбәкстанның Җизак шәһәрендә ачылды. Әлеге технопаркның проекты Рөстәм Миңнехановның узган елның октябрендә бу шәһәргә эш сәфәре нәтиҗәләре буенча тормышка ашырылды. Ул вакытта Үзбәкстан Президенты белән очрашу барышында икенче уртак технопарк булдыру турында килешү төзелгән иде. Яңа территориянең үсеш планын Казандагы «Химград» белгечләре әзерләгән. Биредә киммендә 36 резидент өчен 1100 эш урыны булачак дип көтелә. Инвестиция күләме – 60 миллион доллар. Технопарк чит ил җитештерүчеләрен, шул исәптән Россия компанияләрен дә Үзбәкстанда туплауны һәм уртак эшчәнлекне көчәйтүне күз уңында тота.

– Без Россия – Үзбәкстан дуслык мөнәсәбәтләре кысасында Үзбәкстан белән хезмәттәшлекне үстерү мөмкинлекләрен югары бәялибез. Бу эштә ике дәүләт Президентлары Владимир Путин һәм Шәүкәт Мирзиёевның өлеше зур, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рәис моннан бер ел элек Ташкент өлкәсендә ачылган «Чирчик» технопаркын да телгә алды. Бүген анда 127 миллион долларлык 20 инвестиция проекты гамәлгә ашырыла. Продукция Казахстанга һәм Таҗикстанга озатыла.

Үзбәкстанда Рөстәм Миңнеханов КФУның Җизак шәһәрендә ачылган яңа филиалы – Медицина белем бирү үзәгендә дә булды. Биредә геология, икътисад, журналистика, лингвистика, медицина биохимиясе, дәвалау эше, стоматология кебек юнәлешләр буенча белгечләр әзерлиләр, шулай ук тикшеренүләр белән шөгыльләнәләр.

– Бүгенге кебек катлаулы шартларда да нәтиҗәле сәүдә-икътисадый һәм гуманитар-мәдәни элемтәләрне саклап калдык, хезмәттәшлекне алга таба да ныгытабыз, – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов Үзбәкстан Премьер-министры Абдулла Арипов белән очрашуда.

Премьер-министр билгеләп үткәнчә, мондый очрашуларның уңай нәтиҗәсе буларак, ике арада товар әйләнеше үсә.

– Һәр очрашу барышында яңа объектлар ачыла. Бүген сез «Җизак» технопаркы ачылышында катнаштыгыз. Ул «Чирчик» кебек үк уңышлы эшләячәк дип ышанам, – диде Абдулла Арипов.

Эш сәфәре кысасында Рөстәм Миңнеханов Үзбәкстан Президенты Шәүкәт Мирзиёев белән дә күреште. Рәис дәүләт башлыгына Татарстанның Үзбәкстандагы проектларына шәхсән теләктәшлек белдергәне өчен рәхмәт әйтте. Ике ил Президентларының үзара ышанычка нигезләнгән мөнәсәбәтләре төбәкләргә дә хезмәттәшлек итәргә мөмкинлек бирә, дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов. Аерым алганда, ул Үзбәкстанда яңа ачылган «Җизак» технопаркы һәм Медицина белем бирү үзәге турында әйтте.

– Бу – Татарстан һәм Үзбәкстан арасындагы мөнәсәбәтләр кысасында билгеле вакыйга. Ул безнең илләр арасындагы хезмәттәшлекне үстерүгә бәйле яхшы ниятләрнең бер дәлиле булып тора, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Уртак проектларның нәтиҗәлелеген Шәүкәт Мирзиёев та билгеләп үтте. Узган ел Татарстан белән Үзбәкстан арасында товар әйләнеше 290 миллион доллардан артып киткән. Үсеш 50 процент тәшкил иткән.

Рөстәм Миңнеханов Россиянең мөселман илләре белән элемтәләрне җайлау мәсьәләсенә аерым тукталды. Быел Россия Президенты Владимир Путин карары белән «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum»ның федераль дәрәҗәгә ия булуын да әйтте ул. Үзбәкстан делегациясен майда узачак җыенга кунакка чакырды.

Үзбәкстанда «Иннопром. Үзәк Азия» халыкара сәнәгать күргәзмәсе дә узды. Анда Татарстаннан «Алабуга» махсус икътисадый зонасы, «Химград», «Таткабель», Казан вертолет заводы, «Казанкомпрессормаш» кебек 70 компания вәкилләре катнаша, дип хәбәр итте Татарстан сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Коробченко.

Июнь ахырында хисап тоталар

29 июньдә Казанда «Татарстан – Яңа Гасыр» («ТЯГ») Республика иҗтимагый хәрәкәтенең унынчы хисап-сайлау съезды узачак. Иҗтимагый хәрәкәтнең Югары Советы утырышында шундый карар кабул ителде. Идел буе дәүләт су транспорты университетының Казандагы филиалында узган очрашуда хәрәкәт әгъзалары уставны үзгәртү буенча тәкъдимнәрне карады, оештыру мәсьәләләре буенча фикерләште.

Дәүләт Советы депутаты, «ТЯГ» Республика иҗтимагый хәрәкәте Югары Советы рәисе урынбасары Марат Галиев утырышта катнашучыларга республикадагы иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисадый вазгыять турында сөйләде.

– Санкцияләр шартларында импортны алыштыру буенча гаять зур эшләр башкарылды, – диде Марат Галиев. – Минемчә, сәнәгать предприятиеләренең, башка тармакларның бер йодрыкка тупланып эшләве нәтиҗәсендә икътисадның түбәнгә тәгәрәвенә юл куелмады, чикләүләргә бәйле кыенлыкларны җиңүгә ирешелде.

Аның әйтүенчә, расланган бер генә дәүләт программасы да туктатылмаган яисә кыскартылмаган. 13 илкүләм проектта катнашу республиканы үстерүгә өстәмә этәргеч биргән. Узган елда аларны тормышка ашыруга 43,8 миллиард сум юлланган. Шул исәптән федераль бюджет хисабына – 32,5 миллиард сум.

Утырышта шулай ук «ТЯГ» хәрәкәтенең алда торучы сайлау кампанияләрендә катнашу мәсьәләләре дә каралды. 2024 елда – Россия Президентын, шуннан соң җиденче чакырылыш Татарстан Дәүләт Советы депутатларын сайлау үткәреләчәк. 2025 елда – Татарстан Республикасы Рәисен һәм җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарын, 2026 елда – тугызынчы чакырылыш Россия Дәүләт Думасына сайлау көтелә. «ТЯГ», праймериз рәвешендә, «Бердәм Россия» белән берлектә, шулай ук мөстәкыйль рәвештә, үз кандидатларын тәкъдим итү һәм күзәтүчеләр әзерләү аша, сайлау кампанияләрендә катнашып килә», – диде Марат Галиев.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Галиуллина** Румия Шакир кызы, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең оештыру һәм кадрлар белән эшләү бүлеге эксперты **Закиров** Ибраһим Касым улы, «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе баш мөхәррире урынбасары **Ризванов** Габделбәр Газиз улы, хезмәт ветераны **Сәйфуллин** Сәлим Гәрәй улы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе **Тыгин** Александр Васильевич, хезмәт ветераны **Хәбибуллин** Флүн Шәмселгариф улы, Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Актаныш муниципаль районы буенча бүлеге башлыгы – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелеге баш дәүләт инженер-инспекторы **Хәкимов** Илдус Маһиян улы, Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе финанс контроле бүлеге башлыгы **Хуҗина** Рима Нурулла кызы, Татарстан Республикасы үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Чүпрәле муниципаль районы буенча бүлеге башлыгы – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелеге баш дәүләт инженер-инспекторы **Шәйхатдаров** Илдар Иршат улы, хезмәт ветераны **Яковлев** Александр Васильевич, милләтләр арасында татулыкны һәм тынычлыкны ныгытуга, татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Кыргызстан Республикасының «Туган тел» татар-башкорт мәдәни үзәге» иҗтимагый берләшмәсе әгъзасы **Насыйров** Рафикъ Рәхимҗан улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

Имзалы бурыч

Хәрби хезмәт

Узган ел Татарстанда 2 меңләп кеше контракт буенча хәрби хезмәт узу өчен гариза язган. Быел саннар күбрәк булыр дип фаразлыйлар. Ел башыннан бирле республикада яшәүче 1 меңләп ир-ат шундый килешү төзегән инде.

Контракт буенча хәрби хезмәткә алыну өчен гаризаны хәрби комиссариатка барып та, Дәүләт хезмәтләре порталы аша да тапшырырга мөмкин. Электрон гаризаны Россия Оборона министрлыгы сайтындагы шәхси кабинет аша да юлларга була.

– Ул гариза электрон рәвештә безнең сайлап алу пунктына киләчәк. Бу кандидат белән үзебез элемтәгә кереп, алга таба нәрсә эшләргә кирәклеген аңлатабыз, – ди Контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алуның Казандагы пункты җитәкчесе Евгений Токмаков. Аның сүзләренә караганда, хәрби хезмәтнең әлеге юлын сайлаучылар 3–4 айдан башлап биш елга кадәр килешү төзи ала. Егетләр кием-салым, барлык кирәк-ярак белән тулысынча тәэмин ителәчәк, дип тә ышандыралар.

– Контракт төзер алдыннан, егетләргә барлык шартларны яхшылап аңлатабыз. Юкса узган ел контракт төзүчеләр арасында, безне аңлатып бетермичә алдадылар, дип уйлаучылар да булды. Янәсе, алар дүрт айга гына контракт төзегән булган, килешү вакыты чыкса да, аларны кайтармыйлар икән. Әмма Президент Указы бар, анда барысы да күрсәтелгән. Өлешчә мобилизация бетерелү турында карар чыкмыйча, алар контракт вакыты чыккан очракта да кайта алмый. Бу очракта өч төрле искәрмә генә була ала: әгәр хәрби хезмәттәге ир-атның яше тулса, аны хәрби хезмәткә яраксыз дип тапсалар яки аңа каршы җинаять эше кузгатып, ирегеннән мәхрүм итсәләр. Бары шул очракларда гына ул контракт буенча хәрби хезмәттән азат ителәчәк, – дип аңлатты Евгений Токмаков.

Әле күптән түгел генә хәрби хезмәткә бәйле тагын бер яңалык гамәлгә керде. Моңа кадәр урта һөнәри яки югары белеме булган кеше хәрби хезмәткә алынмыйча гына турыдан-туры контракт буенча хезмәт итә ала иде. Хәзер 18 яше тулган, запаста булмаган кеше дә, контракт буенча хезмәт итә ала.

– Контрактны 18–60 яшьлек ир-атлар төзи. Әгәр кандидатның белгечлегенә кытлык зур булса, 65 яшькә кадәр дә контракт төзергә рөхсәт ителә, – ди Евгений Токмаков.

Россия Президенты Владимир Путин махсус хәрби операциядә катнашучыларга бирелә торган түләүләрне тигезләү тәкъдимен хуплады. Билгеле булганча, Федерация Советы Рәисенең беренче урынбасары Андрей Турчак күптән түгел шундый тәкъдим белән чыккан иде. Аның фикеренчә, махсус хәрби операциядә катнашкан хәрбиләргә бирелә торган түләүләрдә гаделсезлек сизелә. Әйтик, мобилизация башлангач, бирегә үз теләге белән киткән кешегә бер тапкыр 195 мең сум акча бирелә. Аның кайда кем булып хезмәт итүе дә мөһим түгел. Контракт буенча катнашучыга исә бу акча ул алгы сызыкта булган очракта гына түләнә.

– Сез күтәргән мәсьәлә бик мөһим. Кулына корал тотып, Россия өчен көрәшүчеләр өчен шартлар тигез булырга тиеш. Безгә кешенең кайсы төркемгә керүе түгел, аның Ватанына карата булган мөнәсәбәте мөһим, – диде Владимир Путин Турчак белән очрашуда.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЯРАМЫЙГА КАРЫЙМЫ?

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Республикада яшәүче һәр кешегә, әби-бабайларны һәм яңа туган балаларны да кертеп, 15 литр хәмер (сыра исәпкә алынмаган) туры килә, ди белгечләр. Бу яктан иң зур күрсәткечләр Югары Осланда (22,6 литр) һәм Лаешта (19,4 литр) теркәлгән. Аксубай (7,3 литр), Чүпрәле (8,2 литр), Спас (8,6 литр) һәм Тәтеш районнарында (9,4 литр) бер кешегә иң аз күләмдә хәмер туры килгән.

– Узган ел республикада яшәүчеләр күбрәк апрель (+7%), май (+8%) һәм июнь (+10%) айларында эчкән, – дип сөйләде Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясенең еллык коллегиясендә тармак җитәкчесе Җәүдәт Әхмәтханов.

Республика наркология диспансерының баш табиб урынбасары Илдар Таҗетдинов әйтүенчә, бу өстән кушып кына хәл ителә торган мәсьәлә түгел.

– «Коры закон» нәрсәгә китерергә мөмкин икәнне беләбез бит инде. Илдә мондый тәҗрибә булды. Эчкән кеше ничек тә җаен таба ул. Идән астыннан аккан көмешкәгә сорау артачак, шул гына. Мин мондый тыюларны хупламыйм. «Коры закон» кертергә тотынганчы, тиешле җирлек булдырырга, ягъни халыкка башка шөгыль табарга кирәк. Ни өчен хәмер эчәләр соң? Шул рәвешле көндәлек тормыштагы кыенлыклардан качып котылырга телиләр. Чәркә артыннан чәркә күтәреп, бөтенләй шешәгә чумалар. Гаиләне ничек туендырасы икән дип баш ватканчы, эчеп исерәсе җиңелрәк бит. Вазгыятьне яхшыртуның бердәнбер юлы – спиртлы эчемлекләр сатуны сәүдәдән чыгару. Ягъни хәмер азык-төлек кибетендә сатылырга тиеш түгел. Аерым сәүдә нокталары булдырсыннар. Ә бездә ничек? Аракы ипи белән сөт янәшәсендә сатыла. Шулай итеп, балаларга кечкенәдән үк, хәмер ул – туклану продукты, дигән фикер сеңдереп үстерәләр. Аермасы: имеш, ул өлкәннәргә генә рөхсәт ителә. Ә балаларның ничек тә тизрәк зур үсәсе килә бит. Шуңа күрә балалар арасында эчкечелек күрсәткече арта да инде. Өлкәннәр белән чагыштырганда, балалар арасында хәмергә бәйлелек тизрәк барлыкка килә. Хәмер сату яки аны тыюга керешкәнче, нишлик дип, «яшел елан»нан зыян күргән гаиләләрдән сорасыннар, – ди Илдар Таҗетдинов.

Рәсми мәгълүматларга караганда, былтыр Татарстанда 609 кеше сыйфатсыз хәмер белән агуланган. Нәтиҗәдә 218 кешенең гомере өзелгән. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 8 процентка күбрәк. Республиканың 12 районында сыйфатсыз хәмер белән агуланучылар күрсәткече республика күләмендәге уртача саннардан да зуррак.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Илдус САФИУЛЛИН, икътисад белгече:

– Татарстанда хәмер сатуга чикләү кертүләренә ышанмыйм. Бүген, киресенчә, кечкенә авылларда да рәсми рәвештә исерткеч эчемлекләр сатуны җайга салу юнәлешендә эш алып барыла. Дөрес, моны көмешкә эчеп агулану очракларын киметергә тырышуга бәйләп аңлаталар. Асылда исә акча мәсьәләсе ята. Төбәк икътисады хәмер сатуга турыдан-туры бәйле. Ә бу – кем әйтмешли, икенче мәсьәлә.

МИЛЛӘТ УМЫРТКАСЫ – ХАТЫН-КЫЗМЫ?

БАШКАЛАГА БӨТЕН ДӨНЬЯДАН 500ДӘН АРТЫК ГҮЗӘЛ ЗАТ ҖЫЕЛДЫ

Хатын-кызга йөкләнгән бурычларның бихисап булуы белән кем бәхәсләшер икән? Заманына күрә артып кына тора бит алар. Берсе үзгәрешсез кала: милләт турында сөйләгәндә, хатын-кызларның шул милләтнең лаеклы кешеләрен тудыручы, тәрбияләүче һәм үстерүче булуын да исәпкә аласы. III Бөтендөнья татар хатын-кызлары съездының пленар утырышында, гүзәл затларның хәзерге көндәге төп бурычы да шул булып кала, дигән фикергә килделәр.

tatar-congress.org

Съездда катнашучы иң яшь туташка – 14 яшь. Иң өлкән делегатка – 87 яшь. Катнашучыларның уртача яше – 41 яшь.

Бергә җыелгач, башкарган эшләр турында хисап тоту табигый инде. Моны «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова башкарды. «Ак калфак»лылар һәм дөнья буйлап таралган туташ-ханымнарның ни эшләгәнен санап тормабыз инде. Киңкырлы эшчәнлек бит: аш-су пешереп, аны хәтта махсус операциядәге солдатларга озату да, мәктәптәге балаларга традицияләрне өйрәтү дә, динне, телне саклау да.

Хатын-кызларның бурычларын барлауны да Кадрия Идрисова башлап җибәрде. Бар да гади югыйсә: хатын-кыз табигый функциясен үтәргә, ягъни тормышка чыгарга, балалар табарга тиеш икән. Аннан исә бу балаларны милләтнең телен, гореф-гадәтләрен, нигезен сакларлык итеп тәрбияләргә. Җаваплы эш, бәхәссез. Бүгенге вазгыятьтә моны ничек башкарырга соң? Отышлы чара дип, Кадрия Идрисова йолалар, гореф-гадәтләр аша халык күңеленә якынаюны атады. «Безнең оешма эшчәнлегенең төп таяну ноктелары – күчмә утырышлар, «Калфак туйлары» (мәшһүр хатын-кызлар турында мәгълүмат туплау, өйрәнү чарасы. – **Авт.**), яшүсмерләр, яшьләр белән эшләү», – диде ул. Санап үткән чаралар – тәҗрибә уртаклашу, соклану, яңалык табу, үзенчәлекле милләт булуыбызны күрсәтү урыны да.

– Халкыбыз мәдәнияткә һәм сәнгатькә мөкиббән. Йолаларыбыз, гореф-гадәтләребез – яшәешебезнең төп умыртка баганасы. Умыртка баганасының бер генә өлеше зарарланса да, кеше хәрәкәтсез кала, – диде Кадрия Идрисова.

«Телне, милләтне, гореф-гадәтләрне, ягъни Кадрия Идрисова әйткән умыртканы саклау җәһәтеннән нишләргә кирәк?» дигән сорауга җавап бирердәй чыгышлар күп булды утырышта. Әйтик, «Бала-сити» белем бирү оешмасы директоры, Дәүләт Советы депутаты Альбина Насыйрова мәктәп кысасында башкарылган эшләр һәм проектлар турында әйтте. Съездда катнашучы туташ-ханымнарга алар белән иркенләбрәк танышу мөмкинлеге дә булачак әле. Башкортстаннан килгән Люция Вафина, фольклор, театр коллективлары эшчәнлегеннән тыш, балаларга дастаннар өйрәтүләрен әйтте. Китапханәдә укыйлар икән. Өлкәннәр балаларга дастаннарны аңлатырга булыша, ди. Төркиядәге милләттәшебез Айзирәк Гәрәева-Акчура иҗади эшләр аша ике арадагы эзне суытмый. Дини белем белән дөньяви белемнең әһәмияте турында да сөйләделәр.

Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев исә, чыгышларны тыңлаганнан соң, милләт сакчыларының бар икәнен әйтте һәм булачагына өмет белдерде.

– Мондый кешеләр булганда, милләтебез күпьеллык булыр. Аларга эшчәнлекләре өчен рәхмәт. Еш кына «Татар теле ник кирәк сезгә?» дигән сораулар бирәләр. Мин җитәкче буларак та, татар егете буларак та җавап бирәм: бу – иң мәгънәсез сорау! Ул – әни теле! Татар халкы өчен иң мөһиме – тел. Милләт телсез була алмый, – диде ул.

Васил Шәйхразыев сүзләре белән әйткәндә, киләчәктә милләтнең бер генә вәкиленә дә авыр булды, саклый алмадым, дип әйтерлек булмасын иде. Җиңел чорның булганы юк инде аның. Заманага сылтамыйк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

СЪЕЗД ТУРЫНДА ФАКТЛАР

- Съездда 510 делегат һәм шәрәфле кунак катнашты (Татарстаннан – 102, Россия төбәкләреннән – 266, чит илләрдән 32 делегат сайланган). Алар илнең 53 төбәгеннән һәм 11 чит илдән килгән иде.
- Съезд эшчәнлегендә Португалиядән вәкил беренче тапкыр катнаша.
- Иң зур делегация – Башкортстаннан. Алар 45 кеше килгән.
- Делегатлар арасында 52 фән кандидаты, 32 фән докторы, 15 профессор бар.

ХАТЫН-КЫЗЛАР КӘЕФЕ

Гөлзада САФИУЛЛИНА, Татарстанның халык артисты:
– Бу форумнарның берсен дә калдырганым юк, шөкер. Бүгенге хатын-кызларга нишләргә кирәкме? Иҗат итәргә! Эшләргә! Кыйблабызны югалтмыйча атларга. Вазгыятькә карап, төшенкелеккә бирелмәскә. Заман ул гел уңга-сулга тайпыла. Динебез, телебез бар, иманыбызны сакларга, балаларга дөрес тәрбия бирергә, алардан хакыйкатьне яшермәскә кирәк. Төбәкләрдә, районнарда мөнәҗәт укучылар, фольклор ансамбльләре оештырып йөрим. Фольклор аша барысын да әйтергә була. Аңа җыр да, тарих та, моң да, мәдәният тә, йолалар да сыйган. Хәзерге көндә мәйданга чыгып, әләм болгарга димәгән. Үз эшебезне башкача да күрсәтә алабыз. Аналарның, хатын-кызларның бурычы шул. Милләт аналарына бурычлар гомер-гомергә күп иде. Нишлик? Барысы да безнең кулда, безнең өстә бу.

Роза ТУФИТУЛЛОВА, «Сөембикә» журналының элеккеге баш мөхәррире, «Ак калфак» хатын-кызлар берләшмәсенең элеккеге рәисе:
– Гаилә тәрбиясен алга куеп башлаган идек эшебезне. Гаилә – тормышның таяну ноктасы. Гаилә – эчке дәүләтебез, ул изге тойгыларыбызны сыйдыра, кеше анда тәрбияләнә. Журналда булсынмы, җәмәгать эшендә булсынмы, мин һәрвакыт гаилә мәсьәләләрен алга сөрдем. Аны бернинди сәясәт белән дә чагыштырып булмый. Съездда да яңадан бу мәсьәләләргә кайтуларын хуплыйм.

Альбина ВӘЛИЕВА, Болгариядәге Фән һәм мәдәният буенча халыкара үзәк директоры, филология фәннәре докторы:
– Татарстандагы милләттәшләргә чит илләрдә яшәүче милләттәшләрдән кайнар сәлам алып килдем. Мондый чараларда даими катнашам. Татар хатын-кызлары тамырларга игътибар итәргә тиеш. Съездның Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләрне саклау елында узуы да очраклы түгел. Бу – татар хатын-кызлар өчен зур мөмкинлек. Соңгы елларда бик күп экспедицияләрдә булып, башка милләт вәкилләренең үз телләрен ничек саклауларын өйрәндем. Үзебезнең Идел-Урал буенда яшәүче халыкларның рухи мирасын, тарихын, туган телләрен танытуга өлеш керттем. Киләчәктә дә бу эшне алып барачакмын.

Хәтер яңарту

Татарстанда бишенче мәртәбә «Җиңү диктанты»н язачаклар. Быел әлеге чара узачак урыннар саны шактый арткан, катнашучылар да башка еллардан күбрәк булыр дип өметләнәләр. Тарихи хәтерне барлауга 45 минут вакытны кызганмыйк, ди алар.

Быел Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына багышланган «Җиңү диктанты» халыкара патриотик акциясе 27 апрельдә узачак. Бу хакта «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе Гөлнара Габдрахманова хәбәр итте.

– Бүгенге вазгыятьтә әлеге чараны аеруча актуаль дип саныйбыз. Хәер, Бөек Ватан сугышы вакыйгалары беркайчан да онытылырга тиеш түгел. Безнең буын әлеге сугышта җиңүнең бәһасен аңларга тиеш. Шуңа күрә, 45 минут вакытыбызны кызганмыйк, әлеге акциядә катнашып, әби-бабаларыбызның батырлыгын кабат хәтеребездә яңартыйк, – диде ул.

«Җиңү диктанты» республика буенча 216 урында узачак. Белемнәрне тикшерү өчен махсус әзерләнгән урыннарның күпчелеге белем бирү оешмаларында урнашачак.

– Быел әлеге чараның 9 Май бәйрәме алдыннан узуы аеруча кадерле. Елдагыча, мәртәбәле кунаклар арасында тыл хезмәтчәннәре, сугыш чоры балалары да булачак, – дип сөйләде Гөлнара Габдрахманова. – Шунысы куандыра: узган елгы чарада җәмгысы 12245 кеше катнашты, шуларның күпчелеге – 25 яшькә кадәргеләр. Быел исә бу сан тагын да артыр дип көтәбез.

«Җиңү диктанты» 25 сораудан торачак. Инде әйтелгәнчә, аларга җавап кайтару өчен 45 минут вакыт биреләчәк. Акциядә катнашырга теләүчеләр, үзләренә уңайлы булган мәйданчыкны сайлап, 27 апрельдә 10.00 сәгатьтә теркәлергә тиеш була. Сорауларга исә 12.00 сәгатьтә җавап бирә башларга мөмкин булачак. Шулай ук онлайн форматта да катнашырга ярый. Моның өчен «диктантпобеды.рф» адресы буенча «Җиңү диктанты»ның рәсми сайтына узарга гына кирәк. Яшь чикләве юк.

Ватан хакына

УЛЫН КӨТҮЧЕ АНА: «Балам яраланганны йөрәгем сизде»

Ана догасы. Аның хәзер бик тә кирәк чагы. Улларын көтүче әниләр әнә шулай ди. Ураза аеның соңгы көнендә якын кешеләре махсус хәрби операциядә булган хатын-кызларны, аларның балаларын җыеп, ифтар мәҗлесе уздырдылар.

– Чын күңелдән укыган догалар кабул булмый калмас, илгә тынычлыкны бары тик гыйбадәт аша гына индереп була, – ди Лаеш районының Нармонка авылыннан килгән Розалия Кәримова. – Улым Илфат өйдән чыгып китүгә, кулыбызга Коръән алдык. Аңа сентябрь аенда повестка килде. 12 ноябрьдә яу кырында иде инде. Нармонкадан гына да 24 егет китте! Ирем дә, киленем дә көн-төн намазда. Доганың никадәр көчле икәнен аңладык инде. Ул авыр хәлдә булганда, йөрәгем сизде. Үземнең дә хәлем авырайды. Балам күп тапкыр яраланып, исән калды. Әле дә дәвалана. Ике улым да бик акыллы булып үстеләр. Әтисе белән миңа «син» дип тә эндәшмәделәр. Хөрмәт итеп, «сез» дип кенә торалар.

Казанда яшәүче Роза апа Абдуллинаның 65 яшьлек ире Раил, өлешчә мобилизация башлануга, үз теләге белән китеп бара. Ике кызы, хатыны да үгетләп карый. Барлык туганнары җыелып та, китмәвен сорыйлар. Яшьләр барганчы, мин барыйм, ди ул.

– Ирем белән хәбәрләшеп торабыз. Кайчак берничә көнгә югала. Шул чакта бик борчылам инде. Май аенда ялга кайтырмын дип тора. Аны белмәссең, кире дә уйларга мөмкин. Кайт инде, дип тә карыйм, җиңмичә кайтмыйм, ди. Шундый кеше инде ул. Иле өчен гомерен бирә торган. Үлемнән дә курыкмыйм, яшәсен яшәдем инде, ди. Миңа бик кыен. Өйдә ир кулы җитми. Элек кар да көрәтми иде. Быел үземә көрәк тотарга туры килде, – ди Роза апа.

Илүзә Хәйбуллованың ире хәрби.

– Кияүгә чыкканда ук иремнең өйдә тормаячагын белдем. Моңа әзер идем. Әмма моның кадәр озакка китәр дип уйламадым да. Ике балабыз бар. Сагынабыз инде. Баштарак миңа бик кыен иде. Сабыр итәргә өйрәндем. Ирем әлегә ялга кайтты. Озакламый китәчәк. «Егетләргә без бик кирәк», – дип кенә тора, – ди Илүзә. – Балалар да сабырлыкка өйрәнде. Мин еласам, тизрәк юатырга тырышалар. Шуңа күрә алар янында моңаеп утырырга тырышмыйм. Күңелдә бары бер теләк: исән генә булсын!

Казанның Кабан арты мәчете имамы Йосыф Дәүләтшин да сүзен ана догасы белән башлады. Андагы егетләр белән үзе дә аралашып тора икән. Бер табиб танышы ай буе тәравих укыган. Үзенә кечкенә генә мәчет тә салып куйган, ди.

– Без үзебез дә егетләр өчен догада булырга тиешбез. Әти-әни догасының нинди икәнен аңлап бетерә алмыйбыз әле. Ул догаларның көче зур, – ди хәзрәт.

Апас районының Багыш авылыннан килгән Гүзәл Зәйнуллина да улы өчен гел догада тора.

– Әлегә ялга кайтты. Сөенеп туя алмадым. Баламны болай озак күрми торганым юк иде. Үзе дә бик сагынган. Илфатыма 24 яшь кенә әле. Бар да яхшы дип кенә тора. Без бармасак, Ватанны кем саклар, ди. Батыр итеп үстерә алганбыз, шуңа сөенәм, – ди Гүзәл.

Кем белән генә сөйләшсәм дә, алар үзләрен Казандагы затлы бинага җыеп, кунак иткән оештыручыларга рәхмәтләрен елый-елый әйтәләр.

Россия мөселман хатын-кызлары берлеге әгъзасы, Казанның Идел буе районы кураторы Илсөя Гәрәева, намаз вакытында күңелдә, рамазан ае беткәнче, ирләрен, улларын көтүче әти-әниләр, хатыннарын чакырып авыз ачтырсаң иде, дигән теләк туды, ди. Әнә шуннан соң ул бу уен Россия мөселман хатын-кызлары берлеге әгъзасы, Казанның Яңа Савин районы кураторы Нурия Шәрипҗановага җиткерә. Икәү уйга калалар. Ничек җаен табарга соң?

– Ирем дә, Аллаһы Тәгалә җаен бирә ул, диде. Уйламаганда хәйриячеләр дә табылды. Безгә кирәкле ресторан да нәкъ бүген буш иде. Бик сөенеп, кунакларны чакырдык, – ди ул.

Нурия Шәрипҗанова белән икесе бу хакта Россия мөселман хатын-кызлары берлеге җитәкчесе Наилә Җиһаншинага җиткерәләр. Ул аларның изге эшләрен хуплап, теләктәшлек белдерә.

– Солдат әти-әниләрен, хатыннарын, сабыйларын сөендерә алуыбызга бик шатбыз. Авыр чакта ялгыз түгел икәнлекләрен аңласыннар. Алар ничек борчылса, без дә егетләр өчен шулай кайгырып торабыз. Догаларыбыз кабул булыр, илгә тынычлык иңәр, – ди Нурия Шәрипҗанова.

Ифтарга килгән берәү дә бүләксез китмәде. Әтиләрен көтүче сабыйларга махсус күчтәнәчләр бар иде. «Әти исән-сау булсын», – дип намазга баскан малайга Коръән китабы бүләк иттеләр.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

БЕРӘҮ БАКЧАГА ЧЫКСА...

Авыл хәлләре

Авылда шундый гадәт: берәү бакчага чыкса, календарьда да, һава торышында да эш юк, калганнар да бакча ягына карый башлый. Язын да шушы хәл, җәен, көзен дә. Эшкә тәвәккәлләргә куркып, шикләнеп торучылар кемнеңдер башлаганын гына көтә.


depositphotos.com

Менә быелгы язда да, берәүдән берәү күреп, акрынлап, яшелчә бакчаларын да эшкәртteләр, орлыклар да чәчтеләр, теплицаларына да кыярдан кала бөтенесен утырттылар. Инде чират бәрәңге бакчаларына җитте. Юкса 22 апрель иртәсендә күршеләребезнең бәрәңге утыртканын күреп, күпләр: «Бигрәк иртә бит әле, җир дә җылынмаган», – дигән иде. Берничә көн үтүгә, инде авылда бәрәңге утыртучылар арткан булып чыкты. Бездән әллә ни ерак булмаган Яңгул авылында да утырталар икән. Ашыгучыларны аңлап та була: җирнең дымы көнләп-сәгатьләп кими. Көчле яңгырлар явып тыгызламагач, быел җир дә көпшәк, диләр. Дөрес, әле җирнең өсте генә җитешкән, аскы өлеше юеш, зур техникалар белән бакчаларга керә торган түгел. Авылларда бит хәзер күп кешенең мотоблоклары бар, шулар белән эшкәртәләр, утырталар. Бакча тапталмый, балчыгы да тыгызланмый, диләр.

– Кичтән генә күлтиләгән идек, кузгаткач, санаулы сәгать эчендә бакча менә шушындый әйбәт булып җилләгән, ник бер кәсәнкәсе булсын, – ди бәрәңге утырткан күршеләребез.

Алар ел да бәрәңгене иртә утырта. Үткән ел да салкынча вакытта утырттылар. Без әле җир җитешмәгән, «пешмәгән» дип көтеп калдык. Аннан тоташ яңгырлар башланды. Нәтиҗәдә, без бәрәңгене гомер булмаганча, 1 июньдә генә утырта алдык. Аларның бәрәңгеләре, берничә көнгә генә соңарып, искиткеч матур, тигез булып тишелеп чыкты, җылы туфракка утыртканга карап, безнекеләр дә ашыкмады: тиешле көнен тутырмыйча тишелмәде. Безнекеләр «борын төртеп» килгәндә, алар инде беренче кат рәт араларын эшкәртте. Аңа карап, корт та ашап бетермәде. Өстәвенә безнең авылда ел да, август башларында инде бәрәңгегә фитофтора төшә, нинди генә химикатлар белән, ничә тапкыр эшкәртсәң дә, аннан котыла алган юк (су сиптерү-сиптермәүгә дә карамый). Шуңа күрә, үткән ел безнең бик күп булып яралган бәрәңгеләр үсеп туя алмый калды, ә күршеләрнең уңышы искиткеч шәп булды.

– Көз көне бәрәңге казыганда: «Сез кайчан утыртасыз, без дә шул вакытта утыртырбыз әле», – дигән идем, сезгә җитешә торган түгел, болай булса, киләсе елга көздән утыртып калдырасыз икән, – дим, шаяртып, бәрәңге утыртучы күршеләребезнең хәлен белешергә кергәч.

Аларның буразна сызып, элекке кебек бәрәңге утыртуларын күрүгә (үткән ел мотоблокка кечкенә сажалка куеп утыртканнар иде, алай бик озакка китә диделәр), күңелдә матур хатирәләр дә яңарды. Бакчаларны ат белән эшкәртеп, нәкъ шушылай, буразна буйлап йөреп, бәрәңге утырткан еллар. Ян бакчаларның зурлыгы! Фермадагы ике-өч атка берәр ай алдан чиратка язылася. Синең чиратың булган көнне, үч иткәндәй, яңгыр ява. Әле иртәдән яуса бер хәл, бөтен туганнар, күршеләр җыелышып, «менә хәзер ат килә» дип көткәндә генә ява башлый ул. Кайбер елларны шул сәбәпле, берничә тапкыр җыйналып таралышасың. Бер елны без бәрәңге утыртып бетергәндә... буран чыкты. Дулый-дулый кар яуса да, бүленмәдек, утыртып бетердек. Бәрәңгегә зыяны булды дип истә калмаган, аның каравы ел саен искә алабыз.

Ул күршеләр белән бер-беребезгә кулалмашка йөрүләр! Бәрәңге чәйләренең тәмлелеге! Кайсы күршебезнең бәрәңге чәенә дип нәрсә пешергәненә, кемнең бәрәңгене нинди куелыкта утыртуына кадәр истә... Шөкер, бик дустанә, бик күңелле яшәдек. Беребез эшкә тотынса, калганнар булышырга йөгерә идек... Хәзер барыбыз да үзенчә, үзенекеләр белән эшләргә тырыша. Килер кешең булса, алай да рәхәт. Һәр чорның – үз матурлыгы.

Тракторлар кертеп, бакчаларны бозып бетердек, диючеләр булса да, алар белән эшләүнең үз рәхәте бар. Киләләр, күп булса, ярты сәгать эчендә эшкәртеп, утыртып, көзен казытып та китәләр. Бакчаңның капкасын ачып-ябучы кеше булса, шул җитә.

Элекке бәрәңге бакчаларының өчтән бере генә калса да, барыбер, шушы чор җитүгә, авыл кешесенең эченә «корт» керә. Бәрәңгеләр утырткач, ничектер күңелгә рәхәт булып кала шул. «Үзебездән торганын эшләдек», – дибез...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТАТЭНЕРГОСБЫТ

«Татэнергосбыт» хәбәр итә

«Электр энергиясен күпләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын раслау турында» 21.01.2004 ел, №24 Хөкүмәт карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтында (https://mpt.tatarstan.ru/informatsiya-o-proektah-investitsionnih-programm-3469637.htm) һәм «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте сайтында (https://tatenergosbyt.ru/about/open-info/market-subject/investment-info/) «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең 2023–2025 елларга инвестиция программасын төгәлләштерү проекты турында һәм «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең 2024–2026 елларга инвестиция программасы проекты турында тулы мәгълүмат урнаштырылган.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, әнисе
НУРМӨХӘММӘТОВА Нурдидә Хәмәтнур кызы
вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Рәисе Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиеваның авыр кайгысын уртаклаша.

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, әнисе
НУРМӨХӘММӘТОВА Нурдидә Хәмәтнур кызы
вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Рәисе Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиеваның авыр кайгысын уртаклаша.

Свидетельство № 128110, серия 16 об окончании автошколы ООО «Драйв», выданное 27.10.2021 г., на имя Галлямова Алмаза Радиковича, в связи с утерей считать недействительным.

Авыл язмалары

aktanysh-rt.ru

Чүп түгәбез...

Яз җитүгә, авыл кешесенең һәр ел саен кабатлана торган бер хәстәре бар – дөньяны тазарту. Сүз йорт-кура турында, чөнки авыл кешесе өчен төп дөнья – шул, калганнары – чит-ят төбәк кенә. Чисталыкны бөтенебез дә ярата. Ихатаң җыештырылган булса, үзеңне әйбәт кеше кебек хис итәсең. Кергән-чыккан кеше алдында да уңайлы, күзләрне иркәләп балкып тора. Хәтта үләннәр дә иртәрәк яшелләнә башлый. Пөхтә урын аларга да рәхәттер инде. Шуңа авылдашлар, җир кардан арыну белән, җыештыру эшенә керешә. Чисталыкны, әлбәттә, мин дә яратам, тик мин аның кеше кулы белән эшләнүен ныграк үз итәм. Шуңа бераз соңгарак калынды. «Тегеңә кушармын, моннан эшләтермен», – диебрәк йөрдем дә ахыр чиктә үзем тотындым.

Күздән тазартылган дөнья инде ул югыйсә, ләкин хәтсез җыела икән. Әллә кышкы кар астында бөтен биләмәдә чүп-чар үсеп утыра ул? Бәрәңге бакчасын тырмалап та бер өем чүп уңышы алдым. Аннан соң сүтелгән иске сарайларның калдык-постыгы өелде. Черек агачлар, иске такта кисәкләре, тимерчыбык өзекләре, кәкре кадаклар, калай сыныклары, шифер кисәкләре, тагын әллә нәрсәләр. Узган ел мебель алыштырган идек, искеләрен чыгарып түгәргә кирәк. Менә сиңа тагын такта-токта, шөреп, пыяла, көзге… Талашып-сугышып тормасак та, савыт-саба да хәтсез ватылган икән. Пыяла кисәкләрен дә асрап ятарга ярамый бит инде. Әле монда искергән, бозыла башлаган, бозылып бетмәгән ризык калдыклары да, базда черегән, чери башлаган, черергә мөмкин булган, яки суты чыгып йомшарып беткән яшелчәләр дә бар икән. Бәрәңге үзе генә ни тора! Аны авылча куллануның, мәсәлән, иң дөрес, иң яхшы ысулы берәү генә бит инде: күп итеп утыртасың, җәй буе эшкәртәсең, коңгыз чүплисең, көзен мул уңыш аласың һәм кыш буе базда тотасың да язын чыгарып түгәсең. Шул рәвешле, кара исәп белән генә уйласаң да, берәр трактор арбасы булырга тиеш иде. Мин дә күрше егетенә әйттем, ул шул сәгатендә үк арбаны ихата уртасына китереп куйды. Әллә ничә тонна сыешлы зур арба инде ул. Мин аны-моны исәпләп: «Бер йөккә генә бетмәс, ахры», – дип, эшкә керештем.

Чүп-чарың никадәр генә күп булмасын, аны чокып чыгару белән арбага ыргытасы килми. Янында тукталып: «Тукта әле, моның берәр эшкә ярарлыгы юкмы, хаҗәте чыкмасмы?» – дип, чүт кенә уйланып торырга кирәк. Бу – күңел таләбе. Мин дә шундук арбага ташламадым, җыеп чыгарган бөтен нәрсәне аның янына тезеп бардым. Күп инде алар. Җыела бит инде. Әле хуҗалыкны чистартам дип тотынган чакта бөтен нәрсәнең дә чүп булып күренә торган гадәте дә бар. Бер ел буена кирәге чыкмаган икән, димәк, бөтенләй яраксыз. Ел әйләнәсенә ансыз яши алгач, калган гомерне дә уздырып була. Чүп, димәк, ташларга кирәк. Шулай итеп, теге өемгә әллә ничә ел буена эленеп торган кием-салым да, чәйнек-самавыр кебек нәрсәләр дә өстәлде. Хәйран гына пирамида хасил булды.

Ну, пирамида ул – нәрсәдән ясалса да пирамида инде, кадерле нәрсә. Шулай уйлауга, дөньяның күчәре беркадәр күчкән кебек булды, аның белән бергә уй-фикерләр дә үзгәрә төште. «Тукта әле, моны тазартып-ялтыратып җибәрсәң, менә дигән хәзинә бит. Кибеттә 30–40 мең тора», – дип, башта самавырны бер читкәрәк алып куйдым. Чәйнеге дә бөтенләй үк эштән чыккан нәрсә түгел икән, урман-кырга булса да йөртергә ярап торыр. Бу иске дигән киемнәр дә ташларлык түгел икән бит әле, бер кирәкмәсә бер кирәгер, үзем кимәсәм, мохтаҗлыгы булганнарга бирермен. Самавырга гына дип үрелгән җирдән, үзем дә сизмәстән, теге өемне аралый башладым. Чыгарып түксәң, бөтен нәрсә дә чүп бит инде ул, эшкә яратам дисәң – хәзинә. Дөньясы да бик ышанычлы түгел бит әле, ара-тирә су да бирми торалар, утны да өзеп-өзеп алалар. Керосин лампасының да кирәк булуы ихтимал. Менә бу иске табаларны да ташларга ярамый, тавык-чебешкә җим булса да салырга ярар. Гомумән, тимер-томырны аерып кую яхшырактыр – аны бит сатып алырга дип тә киләләр. Шуңа авылның шуграк егетләре кайда тимер күрә – өенә ташый. Ташламаска кирәк, әллә кем булып кыланырга ярамый. Тавык дигәннән, менә бу искергән бодайны, комбикормага кушып, пешкән бәрәңге белән болгатып бирсәң, ярап тора бугай ул. Тавык ашый алырлык нәрсәләрне тагын аерып куйдым. «Ә менә боларын сыерга бирергә була, күршеләргә кертермен», – дип, тагы бер өем ясадым. Агач кисәкләре дә чүп булып ятмасын, җәен көн дә мунча җылытырга туры килә, шунда ягарга менә дигән. Утын сатып ала башласаң да кыйммәт бит инде. Аннан соң, менә бу кирпеч-таш сыныкларын да әрәм итмим әле, фундамент саласы бар ич, шунда кулланырга ярап торыр. Булган нәрсәнең кадерен белергә кирәк.

Кызык бу дөнья: чүп-чар эзлисең икән, бөтен нәрсә чүп булып күренә, ә шуларны эшкә яратырга телисең икән – барысы да яраклы булып чыга. Яраклы нәрсәләрне кулланырга кирәк бит инде, күрәләтә исраф итәргә ярамый. Шулай аралый торгач, теге пирамидадан әллә ничә өем хасил булды. Мин аларны, кураның төрле почмакларына илтеп, тәртип белән урнаштырдым инде. Матур булып торалар. Тәртип белән өелгән һәр чүп-чар матурлык булып күренә икән. Сөендем үзем шуларга карап.

Ә чын-чынлап чүп-чар дип аталырлык нәрсә аз гына калды. Ярый инде, шушы кадәр зур арбага салып торып булмас, кул арбасы белән генә түгеп кайтырмын…

Марат КӘБИРОВ

ОНЫК НИГӘ ТЕЛСЕЗ?

Премьера

Оныкларына тел өйрәтә алмаган татар зыялылары, баласын кирәгеннән артык кайгыртучы әти-әни, гаджеттан аерыла алмаган бала. Камал театры, һәрвакыттагыча, көн кадагына туры килә торган спектакль чыгарды. Язучы Рөстәм Галиуллинның «Күзгә кайтаваз» пьесасын Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев сәхнәләштерде.

«Татар-информ»/ Салават Камалетдинов

Рөстәм Галиуллин әсәре «Яңа татар пьесасы – 2022» драматургия бәйгесендә Татарстан Мәдәният министрлыгының махсус премиясенә лаек булган иде. Спектакльнең жанры – комедия. Профессор Зөфәр Мөхәммәтович ролен Татарстанның атказанган артисты Фәнис Җиһанша башкара. Режиссер Фәрит Бикчәнтәев спектакльне артистның 50 яшьлек юбилеена әзерләгән дә инде.

Туган телне, тамырларыңны, гореф-гадәтләрне белмәү, замана балаларын тәрбияләү проблемасы, буыннар арасында рухи бәйләнеш югалу, телне өйрәтүдә әби-бабайның роле. Комедия тамашачы алдына яшәешебезнең чын мәгънәсендә актуаль булган әнә шул проблемаларын куя. Спектакльдә вакыйгалар профессорлар гаиләсендә бара. Сәхнәдә буеннан-буена китап шкафлары тезелгән. Түрдә – классик стильдәге язу өстәле. Түшәмгә эленгән зур люстра күзлекләрне хәтерләтә. Гомерләрен фәнгә багышлаган татар галимнәре яшәгән фатирны әнә шулай күрсәткәннәр. Пәрдә ачылгач, артистлар, сәхнәгә чыгып, парикларын кия һәм уйный башлыйлар.

Гомерләрен татар теле һәм әдәбияты гыйлемен өйрәнүгә багышлаган, икесенә бергә 100дән артык фәнни эш язган 70 яшьлек Зөфәр Мөхәммәтович белән Минзилә Зәкиевнаның (Эльза Моратхуҗина) үзара мөнәсәбәтләре сокланырлык. Яшь вакыттагы сөю хисләре әлеге ике өлкән кешегә хәзер дә якын, кадерле. Балаларны тәрбияләүдә дә белеп эш иткәннәр. Ике уллары да татарча камил сөйләшә. Тик Аваз (Татарстанның атказанган артисты Алмаз Гәрәев) да, Азамат (Рәдиф Галимов) та әти-әнисе юлын дәвам иттермәгән. Алай гына да түгел, кече уллары: «Татар халкы – үлә торган халык, татар теле – бетә торган тел», – дип фикер йөртсә, олы улларының җиде яшьлек малае (Татарстанның атказанган артисты Раил Шәмсуаров) татарча бер сүз дә белми.

Бер мәлдә геройлар тормышының асты өскә әйләнеп куя. Зөһрә исемле журналист кыз (Татарстанның атказанган артисткасы Айгөл Хәйруллина) гаиләгә телевидение өчен тапшыру төшерү турында сөйләшергә дип килеп керә. Профессорның татарча белмәгән бердәнбер оныгы тапшыруда татарча шигырь сөйләргә тиеш була. Монысы гына җитмәгән, Зөфәр Мөхәммәтовичның идеаль кеше, идеаль ир һәм әти образы да чәлпәрәмә килә.

Пьесадагы һәр образга мәгънә салынган. Бераз күпертелгән булса да, без бүгенге тормышта очрый торган таныш типларны күрәбез. Оныкларына тел өйрәтә алмаган татар зыялылары, баласын кирәгеннән артык кайгыртучы әни, гаджеттан аерыла алмаган бала – барысы да безнең бүгенге тормыштан алынган. Әмма геройлар кыю үзгәрешләр һәм каршылыклар аша камиллеккә омтыла, кылган хаталарын төзәтергә тырыша.

Пьесаның авторы Рөстәм Галиуллин да геройларның прототиплары реаль кешеләр булуын әйтте.

– Минемчә, бу спектакльдә һәркем диярлек үз тормышында булган геройлар белән очрашты. Миңа үземә фикерләрен белдергән һәм язган тамашачыларның күбесе, спектакльдән соң оныкларга һәм балаларыбызга бөтенләй икенче төрле күзлектән карый башладык, диделәр. Үзләрен таныган әти-әниләр дә, әби-бабайлар да, хәтта балалар да булган. Димәк, прототиплар реаль кешеләр булып чыга. Күп кеше, әлбәттә, профессорларны танырга тырышты. Премьерада төрле вузлардан, техник һәм гуманитар югары уку йортларыннан укытучылар бар иде. Техник вуз вәкиле өчен дә, гуманитар вуз вәкиле өчен дә бу профессор гаиләсе таныш кебек тоелды. Ләкин профессорлар – җыелма образ, алар һич кенә дә күлке объектлары түгел. Киресенчә, яратып, хөрмәт итеп эшләнгән образлар. Алар милләткә хезмәт иткәннәр, уллары да мәгънәле, оныклары да – шушы затлы династия дәвамы. Телебезне саклауны, иң беренче чиратта, гаиләдән башларга кирәклеген ахырдан үзләре дә аңлыйлар, – диде ул.

Пьесада чагылдырылган фикерне тормышка ашырып буламы соң? Рөстәм Галиуллин фикеренчә, һичшиксез була.

– Безнең җәмгыятьтә эш күрсәтүчеләр арткан-нан-арта. Ул безнең тормышыбызның бөтен өлкәләренә дә үтеп кереп бара. Милли юнәлештәге эшчәнлек тә артты. Балалары белән русча сөйләшәләр, оныклары татарчаны бөтенләй аңламый, үзләре елый-елый милләт өчен борчылалар, зур-зур грантлар, субсидияләр алып, төрле проектлар башкаралар. Кем өчен? Нәрсә өчен? Әйткәнемчә, эш күрсәтер өчен, эш күрсәтеп күз буяу һәм бары тик акча эшләү өчен. Миннән торса, баласы яки үзе татарча белмәгән кешене, гомумән, безнең татар теле юнәлешендәге эшчәнлекләргә якын да китермәс идем. Шулай да спектакльдә чыгарылган проблемаларны хәл итә алырлык хәлдә әле безнең милләт.

«Татар халкын яратып эшләнгән спектакль». Әдәбият белгече Миләүшә Хәбетдинова спектакль турында әнә шундый фикердә.

– Татар сәхнәсендә күптән шундый шәп комедия күренмәде. Нинди матур үткен телле диалоглар, шәп итеп, нык итеп уйланган конфликтлар… Сәхнәдә – тулы канлы образлар! Искиткеч спектакль! Фәрит Бикчәнтәевнең Рөстәм Галиуллин белән иҗади тандемы озын гомерле булсын. Артистларга аерым рәхмәтемне белдерәсем килә. Һәрбер характер комедиядә үзенчә уйланган, бер-берсен кабатламый. Татар халкына шундый матур күзгә бүләк иттегез! Татар халкын яратып эшләнгән спектакль! – дип язган ул социаль челтәрдәге битендә.

Ләйсән САФИНА

Соклану

ЯШЕЛ ЭЗ

Тәтеш районының Байраш авылында Тәүфыйк абый Йосыпов үзе яшәгән йорт тирәсенә 2000 төп агач утырткан. Хәзер инде урманга ерак барырга кирәкми. Гөмбәсен дә шуннан гына җыялар. Наратның хуш исе – үзе бер дәва. Тирә-якны яшеллеккә күмү аңа авыруларын онытырга булыша. Дөнья соры дисәң – соры, ак дисәң, ак төстә бит ул...

Илдар Мөхәммәтҗанов

Тәүфыйк абыйда табигатьне ярату хисе сигез ел элек арткан. Дөресрәге, бугазына операция ясатып, тавышын югалткач. Хәзер ул өйдәгеләре белән колак аппараты аша аңлаша. Нәрсә әйткәнне аңлап, пышылдап җавап бирергә тырыша. Кайберләрен кулы белән дә ишарәләп аңлата.

– Хастаханәдән кайтуга, бакча артында үсентеләр утыртырга тотынды. Өзлегәсең бит, ял ит, дип тә карадык. Бездән качып, авылның башка урыннарына барып утырта башлады. Авыр булмасын дип, үзебез дә җирне казышырга булыштык, – ди хатыны Тәнзилә апа. – Без бит авыл башында яшибез. Үтеп-китеп йөрүчеләр дә әлеге агачларга карап соклансын, наратлар тирә-якка хуш ис таратсын, бакыйлыкка күчкәч, авыл халкы, балалар сагынып сөйләрләр, диде. Исенә төшкән саен чыкты да утыртты. Авыруын шулай җиңеләйтә. Үсентеләрне үзе дә сатып алды, урман хуҗалыгы да бирде.

Чыннан да, үзе бер урман. Аны тиз генә әйләнеп чыгам димә. Һәр агач үзенә тарта. Кайсыдыр шактый баш калкытса, кайсыдыр әле бик кечкенә. Төрләре дә шактый. Арада алмагач, чия, юкә, зәңгәр чыршы, каштаннар да бар. Монда мең ярым нарат үсә. Юкәләр әле яшь. Аларның саны – 200. Тагын биш-алты елдан ылыс исен юкәнеке басып китәчәк. Бу почмак Байрашның иң тәмле, хуш исле урынына әйләнәчәк әле. Быел яз җиткәч, Тәүфыйк абыйның тагын күңеле кузгалган. Көрәген күтәреп, җиргә яңа үсентеләр төртмәкче булган. Җитәр инде, дип Тәнзилә апа туктаткан. Кызыл китапка кертерлек эшләр башкарган түгелме соң? Кемнең әле өй тирәсенә шуның кадәр агач утыртканы бар, ә?

Урманчы түгел ул… Өйләнгәнче тракторда, аннан колхозда инженер булган, төрле эшләр башкарган. Аннан терлекчелеккә күчкән. Хәзер инде өй тирәсендәгесен тәртиптә тота.

Тәүфыйк абый белән әлеге урманны бергәләп әйләндек. Сабый баладай очынып, агач ботакларына кагыла 63 яшьлек ир. Менә күрегез, дигән горурлану да бар. Үзен дә уздырып, биеккә үрелә агачлары. Әнә хатынына гөмбәләр күп үскәнен дә, арада зурлары да бар икәнлеген әйтергә куша. Шул ук вакытта, авылда яшәү – җәннәт, дип пышылдаганы да ишетелә. Шәһәргә баргач, тыны кысыла икән.

Хәзер инде тәрбияләргә урманы бар аның. Елга ике мәртәбә бар җирне чистартып, тырмалап чыга. Карап тормасаң, хәзер чытырманлыкка әйләнәчәк. Чукып бетермәгәйләре дип, казларын да монда чыгармый. Менә шундый җаваплылык та бар.

– Гадәттә, кешеләр өй каршыларына чыршы, наратлар утыртмаска тырыша. Янәсе, сөенечкә түгел. Менә шундый ырымнарга ышанучылар да юк түгел. Ә сез курыкмагансыз, – дим Тәнзилә апага.

– Утыртмыйлар димени? Үзегез күреп торасыз, нинди хозурлык бит! Аның исен иснәп, 100 яшькә җитәрбез әле. Без ырымнарга ышанмыйбыз. Иң мөһиме, җанга рәхәтлек бирә. Без шуңа сөенеп яшибез, – ди ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ,
РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5316 данә
Гомуми тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 258

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+